**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 245 19.03.2020ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 октябрендәге 231 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 октябрендәге 231 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә турында» гы карары белән расланган) 10 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) «- хезмәт кенәгәсенең билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр»;

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы
Совет рәисе К. К. Гилманов